КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 31

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче; 2019 ел, 30 август, 735 нче, 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктның унсигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы

Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

3.3.29 пунктчада «булдырыла торган» сүзләрен «булдырылган» сүзенә алмаштырырга;

3.3.32 пунктчаның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.81 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.81. Күчемсез милек объектларының дәүләт кадастр бәясен үткәрүне оештыра һәм тәэмин итә, законнар нигезендә кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра, шул исәптән күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясен үткәрү турында гарар кабул итә һәм кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслый.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.83[1] пунктчасын өстәргә:

«3.3.83[1]. Татарстан Республикасының ведомствога караган коммерциячел булмаган оешмаларын (алга таба – коммерциячел булмаган оешмалар) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

коммерциячел булмаган оешмаларны төзү, үзгәртеп кору, бетерү турында карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

идарәнең югары коллегиаль органы әгъзаларын, бердәм башкарма орган вәкаләтләрен башкаручы җитәкчене билгеләп куюны һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуны гамәлгә ашыра;

коммерциячел булмаган оешмаларга чыгымнарын финанс белән тәэмин итәргә (кайтарырга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүне гамәлгә ашыра.»;

4.1.11 пунктының 4.1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ризалыгы белән һәм гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт учреждениеләрен, хуҗалык җәмгыятьләрен, коммерциячел булмаган оешмаларны, шулай ук Министрлыкка караган башка юридик затларны булдырырга.»;

5.2 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык структурасына керүче бүлекчәләр турында нигезләмәләрне, шулай ук Министрлык тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән юридик затларның уставларын һәм башка норматив актларын раслый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин